КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 17 декабрь г.Казань № 1151

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 гыйнвар, 25 нче; 2017 ел, 21 март, 167 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1113 нче; 2019 ел, 20 сентябрь, 861 нче; 2020 ел, 14 август, 684 нче; 2021 ел, 31 май, 399 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1512 нче;

2023 ел, 22 март, 316 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә:

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 21 май, 27 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 17 ноябрь, 1151 нче
карары редакциясендә)

Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә хезмәткәрләрнең һөнәри компетенцияләрен арттыруга юнәлдерелгән чараларны (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) уздыруга бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба шул ук эзлеклелектә – субсидия, чаралар, сайлап алуда катнашучылар) бирү механизмын билгели.

2. Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак тиешле финанс елына субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган).

Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

3. Субсидия тиешле финанс елына әлеге Тәртипнең 1 пунктында каралган максат өчен вәкаләтле органга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

Субсидияләр, оештыру-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә, Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы, сайлап алуда катнашучыларга

(дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) бирелә.

4. Сайлап алуны үткәрү ысулы – сайлап алуда катнашучы тарафыннан җибәрелгән заявкалар (алга таба – заявка) нигезендә, сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып, тәкъдимнәр сорату.

Сайлап алу «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле орган һәм заявкаларны карап тикшерү комиссиясенең сайлап алуда катнашучылар белән үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» системасында электрон рәвештә документлардан файдаланып гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуда катнашучыларның «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

5. Субсидия бирү алымы – чыгымнарны каплау.

6. Субсидия алучыны сайлап алу критерийлары:

әлеге Тәртипнең 7 пунктында каралган сайлап алуда катнашучы тарафыннан тәкъдим ителгән чараларны оештыру һәм үткәрү чыгымнары сметасының субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләренә туры килү;

сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыру датасына кимендә өч ел рәттән чаралар оештыру һәм үткәрү тәҗрибәсе булу;

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бару һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

7. Каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләре:

чаралар үткәрү өчен урыннарны һәм җиһазларны арендалау чыгымнары;

канцелярия, хуҗалык товарлары, сувенир продукция сатып алу чыгымнары;

стенд ясау һәм аны җиһазлау чыгымнары (шул исәптән монтажлау-демонтажлау хезмәтләре, инженерлык-техник хезмәтләре);

реклама-презентация материаллары һәм хезмәтләр чыгымнары;

залларны бизәү хезмәтләре, фотога һәм видеога төшерү, чәчәкләр сатып алу чыгымнары;

тәрҗемәчеләр хезмәтләре өчен түләү чыгымнары;

концерт программасы өчен түләү чыгымнары;

транспорт хезмәтләре чыгымнары;

туклануны, экскурсия хезмәте күрсәтүне оештыру чыгымнары;

ашыгыч медицина ярдәме бригадаларының кизү торулары өчен түләү чыгымнары;

чарада катнашучыларга визаны рәсмиләштерү чыгымнары;

видеотрансляцияләр оештыру һәм сайтлар булдыру чыгымнары;

чараларны оештыру һәм үткәрү өчен гражданлык-хокук шартнамәләре нигезендә, шул исәптән авторлык шартнамәләре нигезендә җәлеп ителгән

белгечләрнең хезмәтләре өчен түләү чыгымнары;

чыгым материаллары өчен түләү чыгымнары;

мәгариф программаларын эшләү һәм үткәрү хезмәтләре өчен түләү чыгымнары;

чарада катнашучыларның, вәкилләрнең, чара регламенты (нигезләмәсе) буенча мәҗбүри булырга тиешле техник белгечләрнең яшәве, туклануы, юл йөрүе өчен түләү чыгымнары;

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә чараны оештыруга, үткәрүгә һәм анда катнашуга бәйле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр өчен түләү чыгымнары.

8. Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + \ldots + З_n,$$

монда $З_1$, $З_2$, …, $З_n$ – әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар суммасы.

Әлеге Тәртипнең 7 пунктындагы икенче – уналтынчы абзацларында күрсәтелгән чыгымнар юнәлешләре вәкаләтле орган тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган оештыручы-җитештерүчеләрнең бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чит ил делегацияләрен, чит илләрдән булмаган делегацияләрне, аерым затларны кабул итүгә һәм аларга хезмәт күрсәтүгә һәм республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган оешмалар һәм учреждениеләр тарафыннан чаралар үткәрүгә акча тоту нормаларын раслау турында» 2014 ел, 4 апрель, 216 нчы карары белән билгеләнгән чит ил делегацияләрен, чит илләрдән булмаган делегацияләрне, аерым затларны кабул итүгә һәм аларга хезмәт күрсәтүгә акча тоту нормаларын исәпкә алып билгеләнә.

Әлеге Тәртипнең 7 пунктындагы унҗиденче һәм унсигезенче абзацларында күрсәтелгән чыгымнар юнәлешләре, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын исәпкә алып, вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

9. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

субсидия бирелгән елның 31 декабренә кадәр үтәүчегә субсидия бирелә торган чараны үткәрү – кимендә 1;

субсидия бирелгән елның 31 декабренә кадәр үтәүчегә субсидия бирелә һәм үткәрелә торган чарада катнашучы ягыннан шикаятьләр саны – 0.

10. Заявканы карау һәм субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү даталарына карата сайлап алуда катнашучы түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормау;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатка Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмый яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

сайлап алуда катнашучының башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмый (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашкан юридик затка кушу, башка юридик затка кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмый;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры (булганда) турында

мәгълүматлар булмау.

11. Сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 10 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздыруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба – дәүләт мәгълүмат системасы) белешмәләре нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында Вәкаләтле органның файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булган очракта Вәкаләтле орган сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 10 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны тапшыруны таләп итәргә хокуклы түгел, сайлап алуда катнашучы күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән Вәкаләтле органга тапшырырга әзер булган очрактан тыш.

«Электрон бюджет» системасында автомат рәвештә тикшерүне гамәлгә ашыруның техник мөмкинлеге булмаган очракта, сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 10 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау сайлап алуда катнашучы тарафыннан «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән әлеге таләпләргә туры килү-килмәү турында тамгаларны электрон рәвештә язып кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

12. Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү вәкаләтле орган тарафыннан «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә төзелә, вәкаләтле орган (ул вәкаләт биргән зат) җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана һәм бердәм порталда заявкалар бирә башлау датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча бастырып чыгарыла һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында https://minzdrav.tatarstan.ru/ (алга таба – вәкаләтле органның рәсми сайты) урнаштырыла.

Сайлап алуны уздыру турында белдерү түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау датасы;

заявкалар кабул итүне тәмамлау датасы (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган бишенче календарь көннән иртәрәк була алмый);

вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләре;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртип белән билгеләнгән даталарга туры килергә тиешле әлеге Тәртипнең 10 пункты белән билгеләнгән сайлап алуда катнашучыларга һәм күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен конкурста катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

сайлап алу критерийлары;

заявкалар бирү тәртибен һәм заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

тәкъдимнәрне (заявкаларны) карау кагыйдәләре;

эшләп бетерү өчен заявкаларны кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кабул итмәү тәртибе, шулай ук аларны кабул итмәү нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия күләме, әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алуның җиңүчесенә бирелә торган субсидиянең максималь, минималь күләмен үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсидияне бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан килешүгә имза куелырга тиешле срок;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

бердәм порталда һәм вәкаләтле органның рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләре беркетмәсен урнаштыру срогы (ул сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 нче календарь көннән дә соңрак була алмый).

13. Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү вәкаләтле орган тарафыннан, заявкаларны кабул итү тәмамлану датасыннан да соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 12 пунктында каралган сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүне формалаштыру тәртибе кебек тәртиптә, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкалар бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән заявкаларны кабул итү датасына кадәр әлеге срок кимендә өч календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр керткәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә сайлап алуда катнашучыларның әлеге Тәртипнең 16 пункты нигезендә заявкага үзгәрешләр кертү хокукы каралган нигезләмә кертелә;

заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.

Вәкаләтле орган тарафыннан бердәм порталда, шулай ук вәкаләтле органның рәсми сайтында сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында белдерү урнаштыру сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамланганга кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

Сайлап алуны үткәрмәү очрагы – әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын

кире алу.

Сайлап алуны үткәрмәү турында белдерү «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә булдырыла, вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда, шулай ук вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла һәм сайлап алуны үткәрмәү сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

Заявкалар биргән сайлап алуда катнашучыларга «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздырмау турында мәгълүмат бирелә.

Сайлап алу бердәм порталда, шулай ук вәкаләтле органның рәсми сайтында аны гамәлдән чыгару турында беледерү урнаштырылган көннән үткәрелми дип санала.

Әлеге пунктның алтынчы абзацы нигезендә сайлап алуны юкка чыгару срогы тәмамланганнан соң һәм субсидия алучы белән килешү төзелгәнче вәкаләтле орган Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә җиңеп булмый торган көч шартлары барлыкка килгән очракта гына сайлап алуны юкка чыгарырга мөмкин.

14. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән срокларда заявкаларны «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаштыра һәм тапшыра, әлеге Тәртиптә тапшырылуы каралган документларның электрон күчермәләрен (сканлаштыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) «Электрон бюджет» системасына кертә.

Бирелә торган заявка сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең яисә ул вәкаләт биргән затның  көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланырга тиеш.

15. Сайлап алуда катнашу максатларында сайлап алуда катнашучы заявкага түбәндәге документларны электрон рәвештә кертә:

вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча тутырылган, сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан имзасы (сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең электрон цифрлы имзасы) куелган, сайлап алуда катнашучының мөһере (булганда) белән беркетелгән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучыга, сайлап алуга бәйле башка мәгълүмат (сайлап алуда катнашучы тарафыннан тәкъдим ителә торган субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечен һәм сорала торган субсидия күләмен кертеп) бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык бирелгән субсидия бирү турында гариза;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан имзасы (сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең электрон цифрлы имзасы) куелган сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртиптәге 10 пунктта билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында белешмә кәгазе (ирекле формада);

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры яки бухгалтерлык исәбен алып бару йөкләнгән башка вазыйфаи зат тарафыннан имзасы (әлеге затларның электрон цифрлы имзасы) куелган, сайлап алуда катнашучының мөһере

(булганда) белән беркетелгән, субсидия күчерү өчен сайлап алуда катнашучы тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә яки кредит оешмасында ачылган исәп-хисап яки корреспондент счеты реквизитларын күрсәтелгән белешмә кәгазе (ирекле формада);

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры яки бухгалтерлык исәбен алып бару йөкләнгән башка вазыйфаи зат тарафыннан имза (әлеге затларның электрон цифрлы имзасы) куелган, сайлап алуда катнашучының мөһере (булганда) белән беркетелгән чаралар оештыруга һәм үткәрүгә чыгымнар сметасы;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры яки бухгалтерлык исәбен алып бару йөкләнгән башка вазыйфаи зат тарафыннан имза (әлеге затларның электрон цифрлы имзасы) куелган, сайлап алуда катнашучының мөһере (булганда) белән беркетелгән субсидия бирүгә исәп-хисап белешмә кәгазе;

сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыру датасына чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле фактта башкарылган чыгымнарны раслый торган түбәндәге документлар күчермәләре: шартнамәләр, түләү йөкләмәләре, накладнойлар, счетлар, счет-фактурлар, сайлап алуда катнашучының вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган башкарылган эшләр актлары;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан имза куелган сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган датага кимендә өч ел рәттән чаралар үткәрү тәҗрибәсе турында белешмә кәгазе.

16. Заявкага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре киң таралган, һәркем файдалана торган мәгълүматны карау өчен билгеләнгән программа тәэминаты чаралары белән документны тулысынча карау мөмкинлеге бирелә торган ачык форматта булырга тиеш һәм алар шифрланмаган яисә аларның эчтәлеге белән махсус программа яки технологик чаралардан башка танышып булмый торган чаралар белән сакланмаган булырга тиеш.

Заявкада булган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә сайлап алуда катнашучы җавап бирә.

Сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявка бирү датасы булып, заявкага «Электрон бюджет» системасында теркәлү номеры бирелеп, аңа сайлап алуда катнашучы тарафыннан имза салынган көн санала.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда сайлап алуда катнашучы заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

Заявкага үзгәрешләр кертү яки заявканы кире алу сайлап алуда катнашучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 14 пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән сайлап алуда катнашучы заявкасын формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә гамәлгә ашырыла.

17. Һәр сайлап алуда катнашучы, бердәм порталда сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән алып заявкалар бирү тәмамланган көнгә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, вәкаләтле органга «Электрон бюджет» системасында тиешле рәсми сорау формалаштыру юлы белән сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләрен аңлату турында иң күбе җиш рәсми сорау җибәрергә хокуклы.

Вәкаләтле орган әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән рәсми сорауга җавап итеп, «Электрон бюджет» системасына аңлатмалар бирүгә рәсми сорау кергән көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, әмма заявкалар бирү тәмамланган көнгә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасында тиешле аңлатма булдыру юлы белән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатма җибәрә. Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә карата бирелгән аңлатма әлеге белдерүдәге мәгълүматның асылын үзгәртмәскә тиеш.

«Электрон бюджет» системасында формалаша торган аңлатмадан файдалану әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә сайлап алуның барлык катнашучыларына бирелә.

18. Сайлап алуны үткәрү максатларында вәкаләтле орган комиссия төзи. Комиссия составы, комиссиянең эш тәртибе вәкаләтле органның боерыгы белән раслана.

Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Комиссия карарлары комиссия утырышында катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

19. Заявкаларны карау комиссия тарафыннан «Электрон бюджет» системасында заявкаларны карап тикшерү өчен вәкаләтле органга һәм комиссиягә кереп карау мөмкинлеге ачылган көннән соң килә торган 20 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле органга һәм комиссиягә «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә.

«Электрон бюджет» системасында вәкаләтле орган тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә кадәр вәкаләтле орган һәм комиссия өчен «Электрон бюджет» системасында бирелгән заявкаларга кереп карау мөмкинлеге бирелә торган дата билгеләнергә мөмкин.

Комиссия сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән заявкаларны ачу көненнән соң килгән бер эш көненнән дә соңга калмыйча заявкаларны ачу беркетмәсен имзалый, алар сайлауда катнашу өчен килгән заявкалар турында түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

заявканы теркәү номеры;

заявка керү датасы һәм вакыты;

сайлап алуда катнашучының тулы исеме;

юридик затның адресы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан соратып алына торган субсидия күләме.

Заявкаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә булдырыла һәм «Электрон бюджет» системасында комиссия рәисенең һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук, аңа имза куелган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда

урнаштырыла.

Әгәр заявка сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм заявканы кабул итмәү өчен нигезләр булмаганда, ул дөрес дип танылa.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә заявканың туры килүе-килмәве хакында карарлар комиссия тарафыннан сайлап алуда катнашучы заявка белән бергә биргән мәгълүматны һәм документларны тикшерү нәтиҗәләре алынган көндә кабул ителә.

20. Заявканы карап тикшерү стадиясендә заявканы кире кагу өчен нигезләр:

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 10 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 15 пунктында билгеләнгән документларның тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмавы);

тапшырылган документларның һәм (яки) заявканың сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатларында заявка составында бирелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе.

21. Сайлап алу түбәндәге очракларда уздырылмаган дип танылa:

заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер генә заявка да бирелмәгән;

заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча барлык заявкалар кабул ителмәгән.

22. Кергән заявкаларны рангларга бүлү аларның керү чиратыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

23. Әлеге Тәртипнең 6 һәм 10 пунктларында күрсәтелгән критерийларга һәм таләпләргә туры килә торган һәм заявкасы чират буенча беренче булып бирелгән сайлап алуда катнашучы сайлап алуда җиңүче дип танылa.

24. Сайлап алуны төгәлләү һәм сайлап алуда җиңүчене билгеләү максатларында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе булдырыла, ул түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе сайлап алуда җиңүчене билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә булдырыла һәм «Электрон бюджет» системасында комиссия рәисенең һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук, аңа имза куелган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда урнаштырыла.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе имза куелган көннән алып өч эш көне эчендә вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, үзгәрешләр кертү

сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге беркетмәнең яңа версиясен булдыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең беренче версиясенә имза куелган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе басылып чыкканнан соң биш эш көне эчендә вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителә, ул вәкаләтле органның боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 15 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнүе.

25. Сайлап алу нәтиҗәләре буенча вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуда җиңүче белән, сайлап алуда җиңүче билгеләнгәннән соң бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә килешү төзелә.

Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ рәвешендә төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куела.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләренең Вәкаләтле органга элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта килешүгә килешүнең яңа шартларын килештергәндә  яисә яңа шартлар буенча килештерелмәгәндә килешүне өзү турында шарт кертелә.

Вәкаләтле орган, кирәк булганда, субсидия алучы  белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

26. Кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә субсидия алучы үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

27. Вәкаләтле орган сайлауда җиңүченең сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве факты ачыкланган очракта яисә сайлауда җиңүче тарафыннан дөрес булмаган мәгълүмат тәкъдим ителгән очракта сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тарта.

28. Әлеге Тәртипнең 27 пунктында каралган нигезләр буенча Вәкаләтле орган сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тарткан, сайлап алуда җиңүче үзе килешү төзүдән баш тарткан, сайлап алуда җиңүче тарафыннан сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән срок эчендә килешүгә имза куелмаган очракта, вәкаләтле орган җиңүче дип танылган сайлап алуда катнашучыдан соң булган тәртип номерындагы сайлап алуда катнашучы белән килешү төзи.

29. Сайлап алуда җиңүче килешү төзүдән баш тарткан, субсидия алучы белән килешү өзелгән очракта, вәкаләтле орган, әлеге Тәртип нигезләмәләренә таянып, сайлап алуны өстәмә уздыру турында карар кабул итәргә мөмкин.

30. Әлеге Тәртиптә, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы зат тарафыннан килешүгә имза кую тәэмин ителмәгән очракта, субсидия алучы килешү төзүдән баш тарткан дип танылa.

31. Вәкаләтле орган субсидия алучыга вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 пунктында күрсәтелгән документларны карау һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган 10нчы эш көненнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Үзәк банкы яисә кредит оешмалары учреждениеләрендә субсидия алучы тарафыннан ачылган исәп-хисап яисә корреспондент счетларына (әгәр Россия Федерациясенең бюджет законнары белән башкасы билгеләнмәгән булса) заявка составында күрсәтелгән реквизитлар буенча субсидия күчерүне гамәлгә ашыра.

32. Субсидия алучы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15нче көненнән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан килешүләр өчен билгеләнгән бертип формада каралган форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыра.

33. Вәкаләтле орган әлеге хисап тапшырылган көннән алып 15 эш көненнән артмаган срокта субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турындагы хисапны тикшерә.

34. Вәкаләтле орган субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

35. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәгә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

36. Бирелгән субсидия вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булганда;

әгәр субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең план буенча күрсәткеченә ирешелмәгән булса, субсидия алучы субсидия акчасын түбәндәге формула буенча билгеләнә торган күләмдә (V) кире кайтара:

$$V = S \times k,$$

монда:

S – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме, сум;

k – субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{t}{n},$$

монда:

t – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәләренең фактта ирешелгән күрсәткечләре;

n – килешүдә субсидия алучы өчен билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең план буенча күрсәткечләре.

Субсидия акчасын кире кайтару күләме исәпләп чыгарылганда коэффициентның бары субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешелмәү дәрәҗәсе чагылдырыла торган уңай мәгънәләре кулланыла.

37. Субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 36 пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срогы бозылган очракта, вәкаләтле орган әлеге срок чыккан көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемен҅ә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

38. Субсидия биргәндә билгеләнгән шартларның үтәлүе өчен, тапшырыла торган документларның һәм белешмәләрнең дөреслеге өчен субсидия алучы җаваплы була.

39. Субсидия акчасыннан нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.